Хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында
ХӘБӘР ИТҮ

Капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турындагы боерык проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез

Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Кукмара шәһәре шәһәр җирлеге, Кукмара шәһәре, Ленин ур., 100 з/у адресында урнашкан, 16:23:260119:62 кадастр номерлы 650 кв.м мәйданлы җир кишәрлегенең капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зонада (ОД) «Кибет төзү (киңәйтү)» рөхсәт ителгән файдалану төре белән:

- җир кишәрлеге чикләреннән минималь чигенешләрне киметү өлешендә 1 нче ноктадан 6 нчы ноктага кадәр – 1,00 м га кадәр, 7 нче ноктадан 8 нче ноктага кадәр – 1,00 м га кадәр, 8 нче ноктадан 1 нче ноктага кадәр – 1,00 м га кадәр (кушымта).

Проектка карата мәгълүмати материаллар исемлеге:[1]

1) 1 нче кушымта

2) 2 нче кушымта.

Гавами тыңлаулар уздыру процедурасы түбәндәге этаплардан тора:

1) гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;

2) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектны һәм аңа карата мәгълүмати материалларны рәсми сайтта һәм (яисә) мәгълүмат системаларында урнаштыру
һәм мондый проектның экспозициясен яки экспозицияләрен ачу;

3) иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проект экспозициясен яисә экспозицияләрен үткәрү;

4) гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;

5) гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

Гавами тыңлаулар үткәрү вакыты 14.02.2025 – 03.03.2025

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү проектлары, капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары буенча гавами тыңлауларда катнашучылар түбәндәге гражданнар була:

үзләренә карата әлеге проектлар әзерләнгән җир кишәрлеге яисә капиталь төзелеш объекты урнашкан территориаль зона чикләрендә даими яшәүчеләр;

шушы территориаль зона чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;

әлеге проектлар әзерләнгән җир кишәрлегенә якын җир кишәрлекләре чикләрендә даими яшәүче гражданнар;

мондый җир кишәрлекләренең яисә аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;

әлеге проектлар әзерләнгән капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре;

тискәре йогынты куркынычы янаган җир кишәрлекләренең һәм капиталь

[1] Исемнәре күрсәтелгән мәгълүмати материаллар санап үтелә.

төзелеш объектларының хокук ияләре– җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төре әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясарга мөмкин булган очракта.

Әлеге рөхсәт соралган җир кишәрлеге түбәндәге территориядә урнашкан: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Кукмара шәһәре.

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектның экспозициясен (экспозицияләрен) ачу урыннары һәм датасы:

1) ТР, Кукмара районы, Кукмара ш., Ст. Разин ур., 63 й. – 14.02.2025 ел
2) ТР, Кукмара районы, Кукмара ш., Ворошилов ур., 44 й. – 14.02.2025 ел
3) ТР, Кукмара районы, Кукмара ш., Ленин ур., 15 – 14.02.2025 ел

Проект экспозициясен (экспозицияләрен) үткәрү вакыты: 14.02.2025 –03.03.2025

Экспозицияне (экспозицияләрне) карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат: эш көннәрендә 8 сәг. 00 минуттан 12 сәг. 00 минутка кадәр, 13 сәг. 00 минуттан 17 сәг. 00 минутка кадәр

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектны, аңа карата мәгълүмати материалларны урнаштыру һәм мондый проектның экспозициясен яисә экспозицияләрен үткәрү чорында гавами тыңлауларда катнашучы идентификация узганнар мондый проектка кагылышлы тәкъдимнәрен һәм кисәтүләрен түбәндәгечә кертергә хокуклы:

1) Гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышын яисә җыелышларын үткәрү барышында язма рәвештә яисә телдән;
2) гавами тыңлауларны оештыручы адресына язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә;
3) Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектның экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу китабында (журналында) язып кую юлы белән.

Гавами тыңлаулар Кукмара шәһәре Башкарма комитеты бинасында (1 нче каттагы 107 нче кабинет) узачак, адресы: Кукмара районы, Кукмара шәһәре, Ленин ур., 15 й., гавами тыңлаулар 2025 елның 03 мартта 17 сәгать 00 минутта башлана[2].

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайтлар турында мәгълүмат һәм аңа карата мәгълүмати материаллар kukmor.tatarstan.ru [3], pravo.tatarstan.ru[4].

Кукмара шәһәре
Башкарма комитеты җитәкчесе В.Н. Андреев[5]

[2] Гавами тыңлаулар уздырылган очракта.
[3] Гавами тыңлаулар уздырылган очракта.
[4] Подлежит опубликованию в порядке, установленном для официального опубликования муниципальных правовых актов, иной официальной информации, и размещается на официальном сайте и (или) в информационных системах.
[5] Җирле үзидарә органы җитәкчесе – иҗтимагый фикер алышуларны (гавами тыңлауларны) оештыручы яисә, әгәр иҗтимагый фикер алышуларны (гавами тыңлауларны) оештыручы күрсәтелгән орган булса, коллегиаль киңәшмә органының барлык әгъзалары тарафыннан имза сала.